ISSN 0136-7110

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ
THE MAGAZINE OF SATIRE AND HUMOUR

ЧАЯН



(CAJAN) CHAYAN

ЯНВАРЬ * 2009 * КАЗАН

Ярый әле,
бәхетемә —
Казаннарда
«ЧАЯН» бар.
Клара БУЛАТОВА.

1

С. АНДРИАНОВ рәсеме.



Фельетон



5 бит



7 бит



Кыр капкасын чыккан чакта...

12 бит



17 бит

?

Уйна да, уйла да!

18 бит



"Мисс Мира–2008" титулына Россия чибәре Ксения Сухинова лаек дип табылды. Әлеге конкурс Көньяк Африка шәһәре Йоханнесбургта уздырылды. Җир шарының миллиардлаган кешесе тын да алмый зур кызыксыну белән конкурс барышын күзәтте һәм Россия кызының тантаналы төстә җиңеп чыгуының шаһиты булды. Ксения Нижневартовск шәһәреннән, студентка. Киләчәктә нефть белгече булачак. Ул кечкенәдән спорт белән шөгыльләнгән. Биатлон, йөзү, нәфис гимнастика аны әүвәлрәк кызыксындырган. Чын спортчыларга хас чыныккан характер, максатка омтылучанлык һәм, әлбәттә инде, табигатьтән мул итеп бирелгән матурлык кызыкайга чибәрләрнең-чибәре, булганнарның-булганы дәрәҗәсенә ирешергә ярдәм иткән. "Үз илем өчен горурлык хисе шатландыра мине", — диде дөньяның җиңүче чибәре.

ЯҢА ЕЛ СЫНАМЫШЛАРЫ

• Әгәр Кыш бабайның борыны сезгә килеп кергәндә кызыл түгел, ә зәңгәрләнгән булса, димәк ул инде кемнәрдәдер булып чыккан.

• Әгәр сезнең хатынызгыз Кыш бабай белән кайнар итеп үбешә икән, киләсе ел сезнең өчен салкын булуы ихтимал.


• Әгәр Кыш бабай сездән акча сорый икән, димәк, ул банкта эшли һәм сез алган кредитны кайтарырга тели.

• Әгәр сез иртә белән торганда кунакларыгыздан кайсыдыр чыршы янында йоклап ята икән, ул Яңа ел бүләкләрен сездән алданрак чөмергән диген сүз.

• Әгәр Кыш бабай сезгә бүләк калдырмыйча, берәр нәрсәгезне эләктереп киткән икән, димәк, кайдадыр кемнәргәдер бүләкләр сезгә караганда кирәгрәк.

А. БРЮХАНОВ.

САНКТ-ПЕТЕРБУРГ.



В. БИБИШЕВ рәсеме.

* * *

Елар чак була, әмма көләбез.
Кайгыны көлеп җиңә беләбез.
Безгә мондый көч килә соң каян?
Чөнки көлүне өләшә "Чаян".

Госман САДӘ.

КАЗАН.

ГЫЙБАРӘЛӘР

• Дәүләт казнасын ныграк каезлар өчен депутатларның теш казнасы таза булырга тиеш.

• Бәке тишегенең ниндилегенә карап балыкның да шундые эләгә.

Рашат НИЗАМИ.



В. ФЕДОРОВ рәсеме (Чиләбе).

Кыш бабай Төркиядә

Алания — туризм үзәге. Россиядән килгән эшмәкәрләр биредә биниһая матур отельләр төзиләр. Шулай бервакыт Россия туристлары иптәшләрен Кыш бабай киеменә киендерәләр. Кар кызы да табыла. Күптөрле бүләкләр, тәм-том сатып алалар да капчыкны шыплап тутырып арбага салалар (Төркиядә кар юк) һәм шәһәр буйлап бала-чаганы бәйрәм белән котлап йөри болар. Билгеле инде, балалар әлеге акциядән бик канәгать кала. Һәм алар киләчәктә һәр Яңа елны рус гореф-гадәтләре буенча каршы алырга теләүләрен белдереп әти-әниләренә ялваралар. Аланиядә 75 милләт вәкиле яшәгәнне исәпкә алганда төрек балаларының рус традициясенә өстенлек бирүе халкыбыз өчен үзе бер мәртәбә.

Шәһәр мэры Хәсән Сипахи-оглы, рус Кыш бабаен алып килсәм, сайлауларда җиңеп чыгуга бер адым була диган фикергә килә һәм, озын-озак уйлап тормыйча Россиягә, туп-туры Кыш бабай резиденциясе Великий Устюгка һәм Кузьмино-Люблиногa (Мәскәү) юл тота. Санта-Клаус белән Кыш бабай хезмәттәшлегенә багышланган Мәскәүдә уздырылган протоколга кул кую церемониясендә дә, нигездә, кышның баш тылсымчысы, теләкләрнең кабул булуы турында сүз алып барылды.

— Хәсән, Алания шәһәре халкы Яңа ел кичендә нинди теләкләр тели? — дип сорадым мин җаен туры китереп Сипахи-оглыдан.

— Яшь егетләр, — дип елмайды ул, — иң беренче чиратта, яшь, чибәр кәләш турында хыяллана. Татар кызларын алар аеруча ярата. Сер итеп кенә әйтәм, ял итәргә килгән берничә татар кызын урлау очраклары да булгалады.

Мин Алания мэрына татар телендә чыккан өч "Чаян" журналы бүләк иттем.

Икенче көнне иртүк шалтыратып Хәсән "Елмаю конкурсы" рубрикасының күңеленә аеруча хуш килүен әйтте һәм, саубуллашып: — Кияү егетләрен каршы алырга әзерләнегез! — диде.

Геннадий ЦЕПУЛИН,

МӘСКӘҮ шәһәре.



Хөрмәтле Чаян! Хакимият безнең чиновникларның әхлакый сафлыгы турында чынлап кайгырта башларга җыена шикелле тоела. Эшне озакка сузмасыннар, ришвәт алмасыннар, үз кесәләре белән бюджетны буташтырмасыннар һәм дәүләт мәнфәгатьләрен катгый үтәсеннәр өчен "Чиновникның мораль кодексы"н кабул итәргә карар кылганнар дип ишеттем. Бәлки бу аларны акылга утыртырга ярдәм итәр?


В. ЗАХАРОВА.

БӨГЕЛМӘ шәһәре.

— Аларны җинаять кодексы белән куркыта алмаганны, мораль кодексы белән өркетерсең, пычагым! — диде Шомбай ага, укучыбызның хатын укыгач.

Гәрәй РӘХИМ:

Кризис яный
бөтен җир шарына,
Мием буйлап яман корт бара...
Ярый әле айга ике тапкыр
Кайгылардан «Чаян» коткара.



В. БОГОРАД рәсеме (Санкт-Петербург).





Дефолтның ун еллыгын Россия дөньякүләм масштабында билгеләп үтте.

• • •

Финанс кризисы чорында электр энергиясен саграк тоту максатыннан чыгып, тоннельнең теге башындагы утны да сүндерәчәкләр, имеш.

• • •

Пыяладан өреп төрле әйберләр ясаучы кинәт төчкереп җибәрә. Һәм, нәтиҗәдә, "ИКЕА" кибете киштәләренә куярлык шәп ваза туа.

Г. СӨНГАТОВА.

КАЗАН.

• • •

— Ни өчен акыллыларга караганда җүләрләр күбрәк?

— Акыллы башлар сафсата сатып вакытны юкка сарыф итә, ә җүләрләр үрчи бирә.

В. ЧЕСНОКОВ.

ТЫМОВСК, САХАЛИН.

• • •

— Исәнмесез! Хуҗагызны күрергә мөмкинме?

— Кызганычка каршы, юк ул бүген.

— Ничек инде?! Әле генә тәрәзәдән күрдем бит үзен.

— Ул да сезне күреп алырга өлгергән шул...

• • •

— Титаникны — профессионал, Нух көймәсен һәвәскәр төзегәнне истә тотып, беркайчан да үзең белмәгән эшкә алынырга курыкма.

• • •

Хәрби комиссариат хезмәткәрләре Николай Валуевка 27 яшь тулганчы аннан качып йөргән.

А. БОРИСОВА.

ВЛАДИКАВКАЗ.

• • •

Тормыш кысаларына сыешмаслык хезмәт хакы алган, дип сөйлиләр.

• • •

Бай кешенең сине сатып алырга мөмкинчелеге бар. Әмма аның бу турыда уйлап та карамавы җен ачуны чыгара.

В. ИГОРЕВ.

КАЗАН.

• • •

— Россиядә кайчан да булса тоталитар режим булырмы?

— Юк. Вертикаль демократия генә.

• • •

— Сездә тормоз сыекчасы бармы?

— Юк.

— Ә тосол?

— Анысы да юк.

— Тәрәзә юу өчен махсус сыекча?

— Бетте.

— Җиңел эчемлекләрдән берни дә тәкъдим итә алмыйсыз инде, алайса?

С. ШӘРӘПОВ.

КАЗАН.

Рубриканы Р. ЗӘКИЕВ алып бара.

Бәйрәмнән соң таңнар аткач...



С. ФӘТТАХОВА рәсеме.



В. ФЕДОРОВ рәсеме (Чиләбе).



Зөфәр ХӘКИМОВ рәсеме.

Ляпин ләпек ярып тарихка керде. Төн урталарында, Т. Гыйззәт урамындагы "Милена" кунакханәсе тирәсендә йөргәндә кулындагы буш сыра шешәсен кая куярга белми азапланды.

Үзәк колхоз базарында эшләүче Борис Ляпин шулчак кулындагы пыяла шешәне кунакханәнең бетон ихатасы артындагы машиналар өстенә томырды. Шешә "Лексус" маркасының арткы тәрәзәсенә ләпелдәп килеп төште.

Диварга яки коймага ләпек ябыштыру — бер хәл, ә шешәне "Лексус"ка ләпелдәтеп кую — бу инде артыгын кылану.

Иномарка хуҗасының Ляпин алдында бер гаебе дә юк бит инде. Алар хәтта бу вакыйгага кадәр таныш та булмаганнар.

"Лексус" хуҗасы Р. Бәдретдинов төнге дискобол, тәгәлрәге, шешәбол китергән зыянны исәпләтергә мәҗбүр була. Зыян 64405 сум тәшкил итә.

Акылың җитмәсә, автомашинага "бәйләнеп" тарихка керүең бик тиз. Кайберәүләр исә аннан да артыграгын кыланалар — кыйммәтле иномаркаларны яндыралар, яисә салоннарын актаралар, хәтта көпчәкләрен дә салдырып алалар.



Ләпел-дек

Әтнә районы Шекәнәч авылыннан Шамил Галимҗанов, үз машинасы тирәсендә кайнашып, шулай бер тарихка ләпелдәде.

Ул, транспорт белән идарә итү хокукыннан мәхрүм ителеп, кулында бары тик вакытлыча рөхсәт кәгазе булган хәлдә, шул документтагы март аена туры килә торган "3"ле санын "6"лыга, ягъни июньгә төзәтеп куйган. Әтнә-Чыпчык авыллары юлында машинасын ЮХИДИ вәкиле туктаткач, Ш. Галимҗанов аңа шул "озайтылган" документын төрткән. Шамил Әһлиевич шундук ләпеккә барып төшә. Ялган документны аннан алалар, ә машинасын Әтнә эчке эшләр бүлегенең түләүле тукталышына кертеп куялар.

Кулыңны тыя белмәсәң, ләпеккә артың ябышуын көт тә тор.

Жанна Гобәйдуллина да авто тирәсендә эшчәнлек җәелдереп җибәргән. Ул, җаваплылыгы чикле "Авто-Драйв" оешмасының бердәнбер оештыручысы да, директоры да буларак, Казанның Пушкин урамындагы 21 нче йортта "В" категорияле автомобиль транспорты йөртүчеләрне укытуга керешә. Эшмәкәрлек итүне теркәү кагыйдәләрен һәм лицензия таләпләрен бозып башкарылган эш аңа 684670 сум керем бирә.

Жанна Михайловнаның акчалары ләпеккә төшкән булып чыкты.

Р. ВАХИТОВ,
Р. КАРИПОВ.

Рәис САФИН

ТАМАША

Татар башын татар ашау
Ата-бабадан килә.
Татарның яман гадәтен
Җен-пәриләр дә белә.

Тәмугны саклаучы җеннәр
Җәннәттә кебек яши.
Җен-пәриләрнең эшләрен
Җенле татарлар эшли.

Ирекkә чыкмак татарның
Юлына каршы төшә.
Яла ягып, әләк язып,
Халкы белән көрәшә.

Ике татар өч төркемгә
Бүлгәләнеп талаша.
Җен-пәриләр ботлар чабып,
Карап тора тамаша.

Бер ише үз илен-җирен,
Бер ише үзен сата.
Телсез, динсез, моңсыз калган
Кабан төбендә ята.

Имансызлар казанында
Үзара тартыш бара.
Көнче-хәсетле татарга
Бармы хикмәтле чара?

Борын заманнар гадәте
Милләткә булды яра.



В. ТАРАСЕНКО рәсеме (Мурманск).

Тәндә җаның торса әгәр

Үзегез беләсез, өлкән яшьтәге кешеләр юкка-барга гына врачка йөгерергә ашыкмый. Бик китереп кысса, нишлисең. Кысан гына тынчу коридорда 2-3 сәгать чират торырга хәлеңнән килсә, син врачка эләгү бәхетенә ирешәсең. Сөенергә ашыкма, бу әле михнәт чигүнең башы гына. Авыруыңны ачыклау өчен анализлар бирергә лабораториягә йөгереп килгәч, ачыклана. Сиңа ашыгыч ярдәм бер ай яки ай ярымнан гына мөмкин икән. Авыртуыңа түзә алмыйча, чиратка язучы шәфкать туташына ялварасың: саламга ябышкандай үзеңнең ике авыр операция кичерүеңне, инвалид икәнеңне, шикәр авыруы белән учетта торуыңны әйтеп карыйсың, ахыр чиктә, мин сезне "Чаян"га язам дип өркеткән буласың. Файдасы юк. Акча түлә, хәзер үк кабул итәбез. Менә шулай.

Өйгә кайтып, йөрәк даруларын кабып, бераз хәл алгач, күптән ишеткән бер мәзәк искә төште. Элеккегерәк елларда җәйге эссе көндә бер авылда була бу хәл. Өйлә җитеп килгәндә Җәмилә әбинең өе яна башлый. Халык җыела, ә янгын сүндерүче Сәлим бабай юк. Бер малайны йөгертәләр пожарныйга, анда да юк. Малай өенә йөгерә. Тыны-көне бетеп килеп керсә, Сәлим бабай тыныч кына чәй эчеп утыра. "Нишләп утырасың, бабай, Җәмилә әбинең өе янып бетә бит!"

Сәлим бабай кулындагы чынаягына өрә-өрә тыныч кына чәй эчүен дәвам итә. "Кабаланма, олан, җәйге пожар тиз генә сүнми ул, җитешермен, чәемне эчеп бетерәм дә барам".

Менә шулай Сәлим бабай, ни әйтсәң дә, безнең шәфкать туташларыннан шәфкатьлерәк булып чыга түгелме соң. Чәемне эчеп бетергәч тә барам, ди бит, ә тегеләр ай ярымнан килерсең диләр. "Карт-коры тиз генә үлми" дия торганнардыр инде. Ә бит югыйсә Путин күптән түгел генә "Кеше врачка ярдәм сорап килгәч, өч көн эчендә ул күрсәтелергә тиеш" диде.

Мин, йөрәктә аритмия башлангач, кардиограмма ясатырга айдан артык чират тордым. Күрсәтелгән көнне, чират зурдыр дип ярты сәгать алдан килсәм, бер кеше юк. Чиратлар барсы да акча каеру өчен генә. Түләсәң шул ук көнне, рәхим ит. Шулай да булсын ди, заманасы шундый. Мәсьәлә шунда, эшли алмаучы, ачка үлмәслек кенә пенсиягә яшәгән өлкән яшьтәге инвалид пенсионерны таламыйча гына ярдәм күрсәтеп булмыймыни?!

Д. МОРТАЗИН.

ТҮБӘН КАМА.



Әкияттә дә киная...



И. АЗИМОВ рәсеме.



Эльвира ДЫШАЕВА рәсеме.



С. ФӘТТАХОВА рәсеме.

Юл котгысыны әллә...

Александр Лебедь үз вакытында: "Россиянең — үз юлы бар икәнлегенә шикләнүчеләр булса, алар безнең юлларда йөреп карасыннар" дип әйткән иде.

Моның республикабыз башкаласы шартларында никадәр актуаль булуын күптән түгел генә Татарстанның Хисап палатасы ачыклады. Ул Казан шәһәре башкарма комитетының КТРИ — Капиталь төзелеш һәм реконструкция идарәсен, шулай ук республика бюджеты хисабына башкарылган юл эшләре объектларын тикшерде.

Бу максатларга 2007 елда һәм 2008 елның беренче яртысында бер миллиард сумнан күбрәк акча бүлеп бирелгән. Кагыйдәләрдән төрле бозутайпылулар исә 528 миллион тәшкил итә. Шуның 6,9 миллион сумы күләме арттырып язылган эшләр өчен түләүгә тотылган.

Тикшерүчеләр Восстание урамында (Бакалея урамыннан башлап Горький шоссесына кадәр участокта) 4 сантиметр калынлыкта булырга тиешле асфальт-бетон катламын тапмадылар. Документлар буенча бу эш былтыр ук башкарылган һәм моның өчен КТРИ подрядчыга, җаваплылыгы чикле "Дорспецстрой" оешмасына 2,3 миллион сум акча да күчергән. Шундый ук бозулар шул ук подрядчы тарафыннан Бондаренко урамындагы (Чистай һәм Ямашев урамнары аралыгында) автомобиль юлына үткәрелгән капиталь ремонт сыйфатын тикшергәндә дә ачыкланды.

— Һава шартлары начар булганлыктан өске катламын салмадык, — дип аңлатты Хисап палатасы коллегиясе утырышында КТРИ җитәкчесе Илгиз Латыйпов.

Быелгы һава былтыргыдан әйбәтрәк булмаса да, аның Хисап палатасы тикшерүе вакытына туры килүе яхшы булды шикелле. Чөнки ревизорлар актлар төзегән арада юлларны тиешле кондициягә җиткереп куйганнар иде.

Аудиторлар икенче подрядчы — җаваплылыгы чикле "Нур-1" оешмасына дүрт объектны файдалануга вакытында тапшырган өчен премияне 4 миллион сумга арттырып түләнгән дип таптылар. Әлеге объектлар төрле чыганаклардан финансланган, ә премия Татарстан Республикасы бюджеты средстволары исәбеннән генә түләнгән.

Капиталь төзелеш һәм реконструкция идарәсе, муниципаль контракт шартларын бозып, кайбер объектларда (Чистай урамы "Автомагистрале" — Әмирхан проспектыннан алып Ямашев проспектына кадәр булган, "Зур Казан боҗрасы"ның Сәетгалиев һәм Декабристлар урамнары участоклары; Әмирхан проспекты — Дементьев урамы автомобиль юлының беренче чираты) "Нур-1"гә лимиттан тыш 199 миллион сум аванс түләгән. Шул вакытта әлеге объектларда эшләр подрядчы тарафыннан контракт буенча билгеләнгән срокларда һәм күләмнәрдә башкарылмаган. Тикшерү вакытына үзләштерелмәгән бөтен сумма 221 миллион сум тәшкил итә иде.

— Әгәр эшләр үтәлмәгән икән — ни өчен түләргә? — дип гаҗәпкә калдылар Хисап палатасы коллегиясендә.

— Алга таба эшләрнең бәясе артуга бармасын өчен, — диде КТРИ җитәкчесе, күзен дә йоммыйча.

Т. ШАТОВ.



Н. ВОРОНЦОВ рәсеме (Санкт-Петербург).



Мәчет янында... чүплек...

Газеталарда басылып чыккан тәнкыйть мәкаләләреннән соң "Әл-Ихлас" мәчетенең сул як дивары буена тезелеп киткән чүп контейнерларын башка урынга күчерү хәстәрен күрерләр дип өметләнгән идек.

"Әл-Ихлас" — демократия җилләре исеп, азмы-күпме дин тоту иреге бирелгәннән соң, бер төркем мөэмин-мөселманның тырышлыгы аркасында, мәрхәмәтле иганәчеләрнең игелекле ярдәмнәре белән, Декабристлар урамындагы "Офицерлар йорты" дип аталган йортларның ишегалдында ташландык хәлдә калган элекке котельный бинасыннан Аллаһ йортына әверелгән мәчет.

Әлеге җаваплы һәм саваплы эшне Миргазиян Саматов (авыр туфрагы җиңел, урыны җәннәттә булсын) үзенең ярдәмчеләре, киңәшчеләре Рәүф Ибраһимов, Әзһәр Вәлиуллин, Рәфкать Әдһәмов, Шәйхетдин Ильясов, Рашит Тимуршин, Камил Зарипов кебек олы йөрәкле кешеләр башкарды. Аларның фидакарь эш-гамәлләре белән мәчет тирәсе дә шау чәчәкләргә күмелде.

Тик мәчет диварлары буендагы чүп контейнерлары, алар тирәсендә кайнашкан күсе төркемнәре аны хурмәсхәрә итә, ямен алып тора. Килгән-киткән кунаклар алдында да уңайсыз. Тирә-яктагы йортларда яшәүчеләр чүп ташларга дип киләләр дә, мәчет янындагы матурлыкны күреп: "Монда чүп ташларга да оялабыз. Безгә рәнҗи күрмәгез инде", — дип зарланалар.

Бу мәсьәлә буенча имзалар җыеп, Мәскәү районы хакимияте исеменә хат та язылды. Көннәрдән бер көнне хакимият башлыгы А. Лобов үзе дә мәчет янындагы хәлләрне күреп китәргә дип килде. Ул хәлне уңай якка үзгәртергә вәгъдә биргән иде. Ләкин, Крылов әйтмешли, "йөк һаман да үз урынында әле". Бу вакыйгага бер ел чамасы үтеп китсә дә, чүп контейнерлары урыннарын үзгәртергә җыенмыйлар.

Рәис САФИН.





Бервакыт Боерган авылы кешеләре үзләренең якташы — бер зур начальникка килеп зарый кыла. "Җирле базада эшчеләр сәнәгать калдыкларын яндыралар, сулыш алып булмый", диләр... Башлык кеше үзе барып тәртип урнаштырырга ниятли. Ул әлеге авылга алты машина белән оператив-тикшерү группасын алып килә һәм тынычлыкны бозучыларны йодрыклары белән тәрбияләргә керешә. Берәүләрнең колак төбенә, икенчеләрнең борын шәрифләренә каты эләгә... Кыскасы, милициянең авыр йодрыгыннан һәм аякларыннан качып котылмаганнарның барысына да өлеш чыга. Берара тәртип урнаштырыла, ә районның әлеге начальнигына карата җинаять эше кузгатыла. Шунысы гаҗәп: тикшерү вакытында начальник сыйфатындагы сугыш чукмары, күзен дә йоммыйча, мин хезмәт инструкциясе кимәлендә гамәл кылдым, дип җавап бирә...

Түбән Каманың оперуполномоченные Андрей М. да шундый ук инструкция нигезендә эш иткәндер, күрәсең. Ул "Түбән Кама шина" җәмгыятеннән автомашина урлауны тикшергәндә кладовщицадан сорауны шундый "тырышып" ала ки, әлеге ханымның колак пәрдәсе шартлый. Инде әлеге "тырыш" хезмәтче, суд карары белән, үзенең йодрыклары көчен бөтәнчә күрсәтә алмаячак.

Ә Казандагы участок уполномоченные Ранас Ш. үз коллегаларыннан аермалы буларак, йодрыклары-на ирек биреп тормаган. Үзе шикле дип санаган адәмне Ибраһимов урамындагы терәк пунктта типкәләгән. Хәлбуки, әлеге адәм, участковыйның сорауларына җавапны бик теләп бирмәгән һәм аның алдында аягын аякка куеп утырган икән ләбаса. Шуның нәтиҗәсе буларак, бу бичара хастаханәдә бер ай ятып чыгарга мәҗбүр булган.

Киров районы эчке эшләр идарәсе хезмәткәрләре Андрей З. һәм Глеб К.ның "хезмәт вәкаләтләрен арттырып файдаланулары" югарыда күрсәтелгән фонда шактый гуманлы булып күренә. Алар яшүсмер кыз белән аның әнисен кабинетка алып кереп кулларына гиргә беркетелгән богау кигезгәннәр. Алар шундый әкәмәт ысул белән әлеге әсирләр аркылы алар янында яшәгән гаепләнүче ханымны милиция бүлегенә китерергә тырышканнар, янәсе.

Юристлар нәзакәтле итеп атаган "хезмәт вәкаләтләрен арттыручылар" аерым кызу канлы служакалар гамәлендә генә түгел, ә бөтен бер милиция бүлекчәсендә дә булып тора. Хәлбуки, узган елның башында "Япеев" милиция бүлегенең дүрт хезмәткәре Казанның Вахитов район суды каршына басарга мәҗбүр ителде. Шыплап тулган маршрут автобусында яшь егет бер ханымга бәрелгән дә, штатский киемдәге милиция хезмәткәренә бу бер дә ошамаган икән. Ул әлеге егетнең яңагына чалтыраткан һәм үзенә ярдәмчеләр чакырган. Тукталышта "хулиган"ны һәм аның ике дустын ике милиция машинасы каршы ала. Кулларына богау салып, аларны милиция бүлегенә алып киләләр, өстәвенә үзләренә "күңелле төн" ясаганчы асылынырга киңәш бирәләр. Моның нәтиҗәсе күңелле төгәлләнми. Ике егет тән җәрәхәтләре белән травпунктка мөрәҗәгать итә, ә өченчесе "уң яктагы бөере зарарланган" дигән диагноз белән хирургия бүлегенә эләгә. Моннан тыш егетләрнең 4800 сум акчасы югалган.

Мондый фактларны тагын күпләп китерергә мөмкин булыр иде. Дөрес, элек тә милициядә ихлас күңелле, мәрхәмәтле Степа дәдәйләр генә хезмәт итмәгән. Мәгәр кыйнау һәм тукмау күренешләре нишләптер соңгы елларда күбәйде. Моның сәбәпләре шактый, ләкин шуларның күзгә иң ташланганы шул: хәзерге вакытта милициядә тәртип һәм законны саклауга караганда "таяк" белән эш итүне өстенрәк күрәләр. Замана Пришибеевлары әнә шуны үтәргә тырышалар. Күрәсең алар таякның ике башлы булуын онытып җибәрәләрдер.

Р. ИСМӘГЫЙЛЕВ.



А. МАМАЕВ рәсеме.



Н. ВОРОНЦОВ рәсеме (Санкт-Петербург).





В. АЛЕКСАНДРОВ рәсеме (Санкт-Петербург).

И. СМИРНОВ рәсеме (Мәскәү).





А. МАМАЕВ рәсеме.

М. СМАГИН рәсеме (Екатеринбург).





М. ФРОЛОВ рәсеме (Ярцево ав., Смоленск өлкәсе.)

Мөхәммәт ӘХМӘТГАЛИЕВ

РӘСЕМ

Рәсем төшергән идем,
Бик килештергән идем:
Үгез йөри болында,
Зәп-зәңгәр күл буенда.

Симезнең дә симезе —
Чып-чын колхоз үгезе.
Зур авызын ачкан да,
Гайрәтләнеп баскан да,
Сузып очлы мөгезен,
Карап тора үгезем.
Әй куркыныч күзләре,
Коточкыч мөгезләре!

...Бозган идем мөгезен,
Юашланды үгезем...



Дамимр Гыйсметдинов — чын, ышанычлы чаянчылар нәселеннән. Аның «Чаян»ның беренче редакторы, атаклы Фәтхи Бурнашның якташы булуы да очраклы хәл түгелдер.

Тагын шуны әйтергә кирәк: Чуашстан Республикасы тәкъдиме буенча ул Фәтхи Бурнаш исемендәге бүләк лауреаты булды.

Бөтендөнья Татар конгрессында эше күп булса да, Дамир әфәнде әдәби эшчәнлеген ташламый. Аның җырлары, шигырь-хикәяләре даими рәвештә республика матбугатында басылып тора.

«Чаян»да да аның өчен ишекләр һәрвакыт ачык. Чөнки ул — безнеке!

Рәшит **ЗӘКИЕВ.**



Дамир ГЫЙСМЕТДИН

ТЕЛЕВИЗОРНЫ — аяк очына

Менә мине генә алыйк. Үсмер чактан бирле гел телевизор каршында. Кемнәрдер батинка туздырып, юкка үзүзләрен кыздырып, вакыт уздырып кызлар артыннан чапкан чакта мин өйдә утырам. Зәңгәр ящектән Ленин, Чапай, Котовский, Пархоменко турында мавыктыргыч кинолар карап. Әти-әни минем трай тибеп йөрмәвемә ифрат сөенәләр иде. Институт-фәләннәр белән кызыксынмагач, ахранга урнашып эшли башладым. Берәүләр эш эзләгәндә хезмәт хакы, премия турында уйлыйлар. Ә мин эшне сайлаганда сакчылар бүлмәсенә куелган телевизорны күреп телсез калдым. Эштә телевизор, өйдә телевизор — дөнья рәхәте. Ул арада әти-әни якты дөньядан китеп бардылар, урыннары җәннәттә булсын, ә мин күптәнге гадәтемә тугры калдым. Башкалар перестройка, демократия, базар шартлары, ваучер-маучер, чубайс-мубайс дип шаугәр килеп саташып йөргән чорда, мин бу галәмәтләрдән ерак тордым. Әйе, телевизордан бразил-мексиканның мавыктыргыч сериалларын карап утырдым. Миңа бандитлар, рикитерлар килмәде: башка кешедә эшем булмады. Өйдән — хезмәткә, ә аннан туп-туры фатирыма. Телевизорым янына. Мин кемгә кирәк тә, миңа кем кирәк?.. Хәер, танышлар арасында: "Өйлән, Гимади, гомерлек буйдак булып каласың бит инде!" — диючеләр булгалады, ләкин мин телевизорны өзелеп яратуымны беркем белән дә уртаклашырга теләмәдем. Дөрес, минем дә кинолардагы шикелле гыйшык тотып, янып-көеп, Фернандолар, Доминголар шикелле мәхәббәткә баштин чумып карыйсым килде. Эштәге ашханә пешекчесе Сания сериалдагы Элизабетка ифрат дәрәҗәдә охшаганга күрә, бер кичне, өйләрне җыештырып, кич утырырга чакырган идем. Чәй эчеп, беркүпме гәпләшкәннән соң, ниһаять, күзебез телевизорга төште. Кунак кызына матур мәхәббәтләр күрсәтү нияте белән ящекне сериал каналына көйләп куйган идем. Ә ул: "Әйдә татар җырларын тыңлыйбыз" дип "ТНВ" төймәсенә басты. Ә анда нишләптер "Кәеф ничек?" тапшыруы урнына сакаллы атакайлар казанский икон-миконны күрсәтеп яталар.

— Бераз көтик инде, хәзер башлана! — дип ялварды Сания. Ә минем "Саташкан мәхәббәт" сериалы инде башланды. Какуй монда көтәргә?! Кыскасы, бик җитди каршылык килеп чыкты, агайне. Нәтиҗәдә кунак кызын тиз генә чыгарып җибәрергә туры килде. Шуның белән минем шашкан мәхәббәтем — вәссәлам!

Шулай итеп тормыш иске калиягә кайтты. Илдә ниндидер гыйкычыпылармыпычыпылар телевизордан күренеп алды. Коммунистларны демократлар алыштырган икән. Чөнки ул дәвердә мин кабат "Санияле" булдым. Шундый исемле затлы япун телевизоры алып, сериалларны төсле сурәттә карый башладым. Менә, ичмасам, бәхет тек, бәхет! Җитмәсә, мавыктыргыч та нәрсә инде шул Барбаралар, Изауралар тормышлары! Ул арада татарлар суверенитет алып, аны югалтып та өлгергәннәр икән. Коточкыч инфляция, дефолт булган чорларда телевизордан йөз серияле Әмрикә киноларын күрсәттеләр. Мин санто-мантоларның язмышы белән янып-көеп яшәгән дәвердә илдә президентлар алышкан, бернична тапкыр депутатлар сайланган икән. Урам себерүче Шиһап абзый әйткәнгә генә колагыма эленеп калган.

Бер көнне ахран башлыгы Хәмит: "Син, Гимади Телевизорыч, пенсеңне оформить итергә онытма тагын…" — дип искәртте.

Их, җегетләр, гомер узган да киткән икән! Дөнья мәшәкатьләрен куганнарга да, минем кебек мыштым яшәгәннәргә дә бер үк сукмак, бер үк язмыш. Әйе… Ахирәт… Анда китәр алдыннан күпләр бик сызланалар, куркуга сабышалар икән. Ә мин андыйлардан түгел. Ник дисәң, Харис энекәшкә алдан ук әйтеп куйдым: "Мине гүргә иңдергәндә әбәзәтелне аяк очына төсле телевизорны төшереп куярга онытмагыз!..". Миңа — шту бу дөнья, шту — тегесе! Карарга телевизоры гына булсын!

20 нче биттәге шаржга күз сал!

ҖӨМЛӘ

Саңгырау, сукыр булмаса да "Ишетмәдем!", "Күрмәдем!" дип, йөз ел яшәде.

Һәйкәлен алсагыз да, нигезен җимермәгез — кирәге чыгар.

СЫНАМЫШЛАР

Әгәр тугызынчы каттан йөзтүбән очкан ир-егетне күрсәгез, аптырамагыз, димәк, кемнеңдер ире командировкадан вакытыннан алдарак кайткан.

Юлыгызны кара мәче, ә аның артыннан эт кисеп узса, бу этле-мәчеле яшәүгә ишарә.

Юлда зур бөкеләр — шәһәргә дәрәҗәле түрәләр килгән.



М. ЛАРИЧЕВ рәсеме (Пушкин шәһәре).





Р. АБЗАЛОВ рәсеме.



МӘСКӘҮДӘ

Муса Җәлилгә һәйкәл

Мәскәүдәге 1186 нчы мәктәп татар телендә белем бирү юнәлешендә эшли. Ул Муса Җәлил исемен йөртә.

Бирeдә Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилгә һәйкәл куелды. Аны ачу тантанасына җыелган халык арасына алма төшәрлек тә түгел иде. Татарстанның Мәгариф һәм фән министры Наил Вәлиев тә килгән иде.

Шагыйрьнең кызы Чулпан үз чыгышында болай диде:

— Үзе ихлас яраткан, шунда укыган, яшәгән һәм Мәскәү аша фронтка киткән шәһәрдә әтиемә һәйкәл куелуга мин бик шатмын.

Пьедесталның ике ягына да Муса Җәлилнең рус һәм татар телендә мондый шигырь юллары уеп язылган:

Мин яшәргә телим бирер өчен
Илгә соңгы йөрәк тибешен.
Үлгәндә дә әйтә алсам иде,
Үлдем, диеп, туган ил өчен!

Геннадий ЦЕПУЛИН.

МӘСКӘҮ шәһәре.

Фәнис ЯРУЛЛИН

ЭШ БАРМЫЙ

Ноябрь дә үтеп бара,
Әле кар да күргән юк;
Кыш соңарып килде быел,
Әйтерсең зур начальник.

Хәер, начальник соңармый,
Ул бары "тоткарлана".
Я ул хәләл җефете белән
"Утырыш" ясап ала.

Яки киңәшмәгә "җыя"
Кызының йокысын өзеп:
"Мә, "биш"ле алып кайт!, —
диеп
Суза кызына йөзлек.

Кызның чырае сытыла:
— Мало, папочка, мало!
Чтобы "биш"ле алырга
Хотя бы биш йөз надо".

Өйдә утырышлар беткәч
Китә түрә эшенә.
Бик арыган кыяфәт белән
Чума кресло эченә.

Сәркәтибенә зарлана:
— Киңәшмә дә, җыелыш.
Ике министрда булдым,
Миннән башка бармый эш.

Әле президент чакырды,
Килгән чит илдән кунак.
Анда сөйлисе сүзләрне
Куярга кирәк уйлап.

— Эшегез күп, —
ди сәркәтип, —
Шуны аңлаптыр инде:
Сезне эштән алырга дип
Менә бит приказ килде!

Приказны салып өстәлгә
Чыгып китте сәркәтип.
Сәркәтип ачкан ишектән
Керде яңа начальник.







Өметсез — шайтан...

Авыл кешесе гомер-гомергә урманга җиләк, гөмбә җыярга йөргән.

Безнең урманнарда аның, агач үсентеләре утыртуда, урман хәзерләүдә һ.б. эшләрдә эшләп, бераз акча юнәтү мөмкинлеге дә бар иде.

Әле күптән түгел генә безнең республика урман җибәрү күләме буенча Россия Федерациясендә беренче бишлеккә керә иде. Эшкә ярамаган агачны да бик теләп алалар иде хәтта. Йомычкадан плитә ясаучы Васильево һәм Идел буе заводларына гына да ел саен ярты миллион кубометр шундый агач-чимал кирәк була иде.

Илебез икътисадчылары 2007 ел башында яңа Урман кодексы тоҗырдылар. Чакыру түгел, урман белгечләре белән киңәшмәгәннәр дә алар.

Яңа кодексның төп асылы нидән гыйбарәт? Урман хуҗалыклары күләгәдә, арткы планда калдырыла, ә алга урман фонды участокларын арендага алган эшкуарлар чыга.

Урман хуҗалыклары җиң сызганып эшлисе урында тик торалар. Ә эшкуарлар нишли диярсез? Ул бүренең киресе, антиподы булып чыкты: күпме генә ашатсаң да ул барыбер урманга әйләнеп тә карамый. Урманда балта тавышлары да сирәгрәк ишетелә башлады.

Без, Шурабаш, Кенәр, Яңа Сәрдә авылларында эшләүчеләр, башта яңа кодекска зур өметләр багларга әзер идек. Әйтик, безнең Тукай урманчылыгында күп еллардан бирле нарат сумаласы әзерлиләр иде. Җыелган сумаланы тимер мичкәләргә тутырып, Горький шәһәренә җибәрә торган идек. Анда шул чималдан канифоль, җилемнәр, политура ясыйлар иде. Сумала әзерләү белән шөгыльләнү сәламәтлек өчен дә файдалы. Яңа Сәрдәдәге танышым Фәридә Гыйльманова 96 яшендә дә өй эшләрен берүзе башкара иде.

Кызганычка каршы, соңгы елларда бу промысел-һөнәрчелек бөтенләй юкка чыкты. Эшкуарлардан берәрсе бу кыйммәтле чималны җыю эшен яңадан тергезеп җибәрмәсме икән, дип өметләнгән идек. Еллар үтә торды, әмма аңа алынучы табылмады. Шулай да өметне өзмибез әле. Өметсез — шайтан, ди.

А. ЖИВИЦКИЙ.

АРЧА районы.

Фәтхулла АБДУЛЛИН

ЗАМАНА ТАВЫГЫ

АВЫЛ САЕН бер мәзәк

Йомышым төшеп Ләке авылына барган идем. Авыл булгач, сыеры-сарыгы да, казы-үрдәге дә булгандыр, билгеле. Әмма мине гаҗәпләндергәне сыңар чеби ияртеп, шуңа мөкиббән китеп йөрүче соры тавык булды. Тавык тиреслектә тибенеп ала да, ашарга яраклы әйбер тапкач, "корт-корт" килеп чебиен чакыра. Сары йомгак кебек сары чеби бәләкәй аяклары белән килеп җиткәнче әнисенең сабырлыгы бетә ахры, тапкан җимен үзе каба да йота. Бәләкәй чеби йөгереп килә дә, әнисе янында бөтерелә, әзләнә, башын әле бер якка, әле икенче якка кыйгайтып ала, үзе бертуктаусыз "чи-чи" килә.

Без хуҗа белән сөйләшеп торган арада бу хәл бернечә мәртәбә кабатлангач:

— Кая моның башкалары? Тилгән алдымы әллә? — дим.

Григорий дәдәй, сөйләп торуда ни мәгънә дигәндәй, башта кулын селтәп куйды. Шуннан соң гына тавыкка ымлап әйтеп куйды:

— Авылдагы тавыклар да бердән артык бала тапмаган замана хатыннарыннан үрнәк ала, ахрысы. Бер чебие чыккан иде, оясын ташлады да китте...

ТҮБӘН КАМА.



Р. АБЗАЛОВ рәсеме.

БЕР УЧМА ХӘБӘР

БУА. Разыя әби Хәертдинова "Чаян"нан төп-төгәл 20 яшькә олы — Яңа ел алдыннан гына 106 нчы яшен ваклады. Ул Янтуган авылында үзе дә сиксәнне "куып" килүче килене Заһирә, аның килене Назимә һәм оныклары тәрбиясендә яши. "Аякларым гына тыңламый" дисә дә, әбинең көн саен капка төбен урап керергә дәрманы җитә икән. Уразасын да тота, намазларын да калдырмый. Кулы гадәтләнгән эшләрдән дә бизмәгән. Абхаз әбиләрен уздыр әле, Разыя әби!

САБА. Ишеткән-белгәннәр Гөлфирә апа һәм Габделкаюм абзый Ширҗановларның беренче балалары Гөлназ турында "Тәбиев кызы" дип шаярталар икән.

Гөлфирә апа кызын ясле-бакчага урнаштыра алмый интегә, шунлыктан аны коляска белән кышкы суыкларда да эшенә йөртә. Беркемнән дә ярдәм күрмәгәч, ул Татарстанның иң зур җитәкчесе булган Фикрәт Тәбиевкә яза. Шуннан соң мәсьәлә хәл ителә. Менә ничәмә дистә еллар инде Гөлназның исемен әлеге игелекле кеше фамилиясе белән бергә телгә алалар. Урынлы булгандыр, күрәсең.

АРЧА. Утар Аты авылы башлыгы, район Советы депутаты Локманов терлек сатып алу өчен банктан максатчан кредит юллый һәм ...сыерлар урынына тугызынчы модель "Лада" автомашинасы сатып ала. Хуҗалыгында 4 баш мөгезле эре терлек булуын раслаучы документы ялган булып чыга.

Депутатны хөкемгә тарталар, ул да, атаклы якташы сурәтләгәнчә, бармаклары бүрәнә ярыгына кысылган Шүрәле хәленә төшә.

ӘТНӘ. Яңа Шашы авылының тау астындагы чишмәсе бүген танымаслык — юлларга асфальт җәелгән, баскычлары — таштан, чәчәк клумбалары ясалган. Чишмәнең күзенә чүп төшмәсен өчен бура куелган, аның бер суы торба аша, икенчесе самовардан ага.

Бу игелекле эшнең иганәчесе, башлап йөрүчесе әтнәле, республикада атаклы кеше, юмор яратучы Фарук Габделхак улы Садыйков.

КӨЛКЕ НИТӘ БИТ УЛ!



Әллә башмагын ашый инде? Ашый-ашый, безне гомер бакый көлдерүче Чарли Чаплин түгелме соң ул?

Шул-шул. Әйткән ди ул: "Мин Фрейдтан (Фрейд Зигмунд — психолог) аермалы буларак, кеше холкының төп күрсәткече секс дип уйламыйм. Ачлык, ялангачлык, хәерчелек кемнең кем икәнен тизрәк күрсәтә".

Шулай булып чыкты да. Көлке белән фаҗига кушылмасыннан тудырылган Чаплин герое рухы белән көчлерәкләрне дә көлдерә алды, күтәрде, коткарды... Америкада.

Бәлки сәер дә тоелыр, тик бүгенге көнебез Американың Чаплинлы көннәрен хәтерләтә сыман. Азык-төлек бәяләре болай бәйдән ычкынса, башмагыңны бәлеш итеп ашаганыңны сизми дә калырсың, Алла сакласын!

Шулай диләр, Рәсәйнең хезмәткә сәләтле һәр унынчы кешесе эштән мәхрүм булып, шымытыр тотып калачак икән. Бу әкәмәттән көләргә дә, еларга да белмәссең. Елыйсы чакларда да көлдерә белә торган Чаплин герое безгә дә кирәкмиме әллә? Кирәк! — дип тибә йөрәк. Ансы безнең халык тупыйкта да туй итәргә сәләтле дә бит. Күпкәрәк китте кебек...

Чаянчы Виктор Смирнов инде күптән тойган бу хәлне һәм "Чаян"га "Елмаю" җыючы рубрика тәкъдим иткән иде. Кем әйтмешли, суга караган, киләчәкне күргән икән. Хәсрәт җанга шәүлә сала, аны елмаю юып ала. Дөньяның кай почмакларыннан гына елмаймыйлар "Чаян"га. Елмаялар, елмайталар, билләһи!..

Ә бүген нәрсә — кара! —
Бу дөнья кая бара?
Җитми акча-азыгы, —
Бетте дөнья кызыгы.

Җитмәсә җитми инде
Тартырга туры килер.
Көчлеләр шул хәлләрдә
Шаяра белер, көлер!

Һәм... яктыртырлар дөньяны!

Шулай итәләр дә. Әнә, күпме мәкаль-әйтемнәр килә "Чаян" укучылардан. Һәм нindиләре бит әле!

Кояшны таптап, ялганны яклап, хаклыкны хата дип булмый.

Елмаю алдында көчен
югалта иблис, карун,
халык канын имүче,
акча корты, гомер бакый
алучы һәм... бирүче

Һәрвакыт һәм һәр җирдә
Яктыртсын юлыбызны
Елмаю дигән кояш.


Эт кояшы этләнсен, —
Аның өчен бервакытта
Кризислар бетмәсен.

Аларга кушылып, кайгы-хәсрәтләрне онытып, җырлап ук җибәрик әле:

Өтмәс диеп уйламагыз, —
Елмаю өтә бит ул.
Мәңге китмәс дигәннәр дә
Бер заман китә бит ул!

Рәшит ЗӘКИЕВ.

С. ТЮНИН рәсеме (Мәскәү).



Рашат НИЗАМИ

БҮРЕ һәм БОРЫЧ

Урмандагы өч печәнче
Утырган ди әбәткә.
Кайнар ашны мактый-мактый
Ашаганнар, әлбәттә.

Тагын эшкә керешкәннәр
Чалгыларын чыңлатып.
Чикерткәләр бии икән
Яшел покос буйлатып...

Кеткмәгәндә ять-яшь бүре
Килеп чыккан табынга.
Табындагы сөякләрнең
Кабып йоткан барын да.

Борычны да әйләндереп
Тел өстенә каплаган.
Төчкерә башлагач кына
Керер урын тапмаган.

Ә хәзерме? Хәзер бүре
Утырган ди акылга.
Хуҗасыз табын күрдеме,
Килми икән якын да.

Тыялмасаң тамакны,
Алырсың шул сабакны.

ОНЫК БЕЛӘН ЯРЫШЫП

Ярты ел саен "Чаян"га
Булмый язылмый калып.
"Нәүәни, мультит талаймын",
Ди онык, миннән алып.

Беренче июльдә тула
Оныгымның өч яше.
Рәсем "укый". Аңа "Чаян"
Мультикларның тәрдәше.

Кадрия САМАТОВА.
АКТАНЫШ районы,
УРАЗАЙ авылы.

Чаян (CAJAN)

Татарча «Чаян»ның индексы — 73488.
Русча «Чаян»ның («Скорпион») индексы — 73489.

Беренче ярты елга язылу бәясе — 108 сум.



КОСМЕТИКА САЛОНЫ



А. АЛЕШИН рәсеме.

ҮЗЕБЕЗНЕҢ АРАДА ЯРЫЙ...

Бер кодагый икенчесенә хәер итеп инде әйләнештән чыккан иске акча биргән.

— Бәй, кодагый, бу акча хәзер гамәлгә ярамый лабаса.

— И-и, кодагый, үзебезнең арада йөрергә ярый ул.

ӘЙТӘМ АНЫ — АРТЫК ТОЗЛЫ!..

Әнисе улына ашарга китереп куя:

— Улым, хатының пешерде, тәмләп аша.

— Чыннан да тәмле булган бу! — ди улы.

Әнисе:

— Ә соңыннан, хатының бала имезгәндә, мин пешереп тәмамладым.

Улы, кашын җыерып:

— Әйтәм аны — шыр тоз булган!

ИКЕСЕ ДӘ ХАКЛЫ

Нечкә хатын белән калын-юан ханым очраша.

Нечкә хатын:

— Сөяк янындагы ит тәмле була ул...

Юан ханым:

— Ә юан хатын эссе көнне иренә ышык, ә салкында шәп җылыта...

ШАМАН
тупламасыннан.

ҖӨМЛӘ

• *Мәхәббәт акыллыларны җүләр итәргә, ахмакларны акыллы итәргә сәләтле.*

• *Әгәр начальнигы үз кулы астындагы ханымны түбәннән дә түбәнрәк сыйпаса, бу ханымны югарырак күтәрелү көтә дигән сүз.*

• *Юньле хатын-кыз булу өчен дә ир йөрәкле булу кирәк.*

В. ЗӘБИРОВ.

ЧӘЧКӘЛЕ БҮЛӘК

Хатыны иренә яңа трусик алып кайткан да әйтә икән:

— Мә, туган көнеңә бүләгем булыр.

— Рәхмәт хатын, ник аның чәчәклесен алдың, хатын-кызныкына охшап тора.

— Охшаса охшар, синең гәүдәңә таман гына, күршебез Рәхмәтулла абзыйның да нәкъ шуның төсле.

Мөнир АБДУЛЛИН.



Е. КРАН рәсеме (Төмән).

Э. ДЫШАЕВ рәсеме.



Василий ШИМБЕРЕВ

Пинсә, пинсә диеп...

Алга киткән капитализмда гражданнар мәңге яшәячәк. Димәк, хәзердән үк пинсәгә чыгу вакытын 75 яшьтән дип билгеләргә. Депутатларның реакцион караштагылары пинсәне 125 яшьтә генә бирә башларга дигәннәр иде дә, прогрессив көчләр басымы астында 75 саны гамәлгә кертеләчәк.

Алга таба, халыкның хакимиятләргә карата ышанычы чиксез булуны исәпкә алып, пинсәнең гомуми күләме ике мәртәбә оптимальләштереләчәк. Хәлбуки, биш елдан соң Русия дөньяда иң куәтле илгә әвереләчәк, аның акчасы да конвертируемый түгел, ә ныклы кимәлдә булачак. (Акча кәгазьләренә алмаз оны кушачаклар.) Димәк ки, пинсәнең сатып алу мөмкинлеге дә артачак. Күпмегә артасын хөкүмәт хәбәр итмәкче иде дә, әмма прогрессив көчләр моңа каршы булды. Чөнки ул хәбәрнең шатлыгыннан илдәге барлык пенсионерларның йөрәк өянәге кузгалу ихтималы бар иде ләбаса.

Хәзер пинсәне үзәкләштерелгән системада бирәчәкләр. Ягъни, бары тик Мәскәүдә генә. Бу гамәл пенсионерларны урындагы чиновниклар һәм реакцион көчләрнең хәрәмләшүеннән азат итәчәк. Ну, аларны, муеннары асларына килгерләрене!

Пинсәнең бер өлеше пенсионерның үз алдында илебезнең югары технология белән коралланган предприятиесенең югары керемле акциясенә салыначак. Һәм ул акцияләр аның хуҗасына, ягъни пенсионерга, коточкыч күп керем китерәчәк. Бу керемгә компьютер, суыткыч, хәтта автомобиль сатып алырга мөмкин булачак.

Барлык льготалар үзләренә тәңгәл нәрсәләргә алыштырылачак. Дөресен генә әйткәндә, күпкә югарырак акчалата компенсациягә әйләндереләчәк. Әйтик, телефон өчен өч сум компенсация болай караганда аз булып тоелырга мөмкин. Әмма якын киләчәктә безнең кыйммәтләнгән өч сумның күпме торасын үзегез дә сизәрсез. Хәзерге йөз сумга киләчәк буын кешеләре "Волга" яки "Мерседес" сатып ала алачак. Кайсын сайлыйсың — рәхим ит.

Русия кешеләре авырмый башлаячак. Сәпсим.

Эшләр менә шулайрак тора. Инде тынычландыгызмы? Ә хәзер процедураларга юнәлегез, аннары — палаталарыгызга кереп ял итәрсез...

С.-ПЕТЕРБУРГ шәһәре.



Бер мосафир Мәскәү урамында берәүдән:

— Кремльгә ничек эләгергә? — дип сорый.

— Сез Петербургтан килдегезме?

— Юк, Воронеждан...

— Ул чагында икеле...

• • •

— Миңа ябыктыра торган таблеткалар бирегез әле.

— Гафу итегез, сеңелем, мин сезгә биш минут элек кенә ун упаковка бирдем ич.

— Минем тамагым туймады.

• • •

Ике редактор сөйләшә:

— Мин "Депутатларның күбесе — сатлык җаннар" дигән мәкалә язган идем. Хәзер газетабызны ябалар!

— Ни өчен?

— Дәүләт серен чәчеп йөргән өчен!

— Их, дускаем, безнеке дә ябыла бит.

— Нәрсә булды тагын? Син мәкаләңне "Барлык депутатлар да намуслы һәм лаеклы кешеләр" дип исемләгән идең ләбаса?!

— Белә торып ялган мәгълүматлар тараткан өчен ябалар безне.

• • •

Халыкның сәламәтлеген саклау өчен керәштә иң югары нәтиҗәләргә статистика ирешә...

• • •

Улы әнисенә хатны болай дип яза:

"Исәнме, әнкәй. Без әйбәт яшибез. Күптән түгел балабыз туды. Әнисенең сөте булмагач, без аны кара хатынга имезергә бирдек. Ышанасы да килми, әнкәй, шуннан соң баланың бите чем каралды!"

Әнисе улына:

"Беләсеңме, улым, мин биш бала үстердем. Күкрәк сөтем булмау сәбәпле барыгыз да сыер имеп үстегез. Әмма арагызда бары тик синең генә маңгаеңа мөгезләр үсеп чыкты".

• • •

— Минем абый машиналарны бик шәп белә. Күптән түгел яңа төр машина җыеп куйган иде. Шассие «Порш-911»неке, «БМВ» моторы куйды, тәгәрмәчләре «Феррари»дан, тизлекне алыштыру тартмасы алты йөздән...

— Нәрсә бүләк итеп бирделәр үзенә?

— Бүләк, дип... Биш ел бирделәр.

ЧуАр пресса

РЕКОРД ЧИРЕ

Француз Мишель Лотитоп 48 ел вакыт эчендә 18 велосипед, 15 супермаркет арбасы, 7 телевизор, 2 карават, бер пар чаңгы, бер компьютер, бер табут ашап бетергән. Бу бәндәнең ашказаны ничек түзгән, чыдаган икән! Америкалы Кевин Шелли башы белән бәреп, бәдрәфтәге агач утыргычны ваткан. Германиядән Томас Фогель бер минут эчендә 56 хатын-кызның лифчигын чишеп җибәргән.



АВТОМАТ-УНИТАЗ

Японнар ясаган унитаз европалыларның исен китәргән. Бәдрәфкә керү белән кондиционер эшли башлый. Унитазның утыргычы янына килүгә аның капкачы ачылып китә. Утыруга гәүдәнең арткы өлешенә җылы һава бөркелә. Музыка уйный башлый. Йомышыңны йомышлагач, европалылар куллана торган туалет кәгазе урынына нәзек торбадан килгән җылы су барысын да хәл итә. Аннары җылы һава киптерә. Су юып төшергәч, унитаз ялтырап кала. Безгә андый унитазлар кайчан килер, дип көтәргә кала.



КӘҖӘ ТӘКӘСЕ МУЗЕЕ

Тверь шәһәрендә кәҗә тәкәсе музее ачканнар. Мондый музей Җир шарында бердәнбер икән. Бу хайванга шундый хөрмәт күрсәтү бер дә юкка гына түгел. Тверь губернасы күп еллар буена кәҗә тәкәсе тиресеннән тегелгән әйберләр белән сәүдә иткән. Музейда кәҗә тәкәсе белән бәйле күп кенә экспонатлар куелган.



Тупламаны **М. АБДУЛЛИН** әзерләде.

КҮҢЕЛЛЕ КУНАКЛАР

Чит ил басмаларыннан шаян рәсемнәр



Д. БОСКО (Бразилия).



МОА (Бразилия).

Оныгым күзләрен аннан ала алмый, чекрәеп карап тора. Гөрзи дәһшәтләре булган таягы белән моннан берничә минут кына элек бөтен залны дер селкетеп торган абыйсы бик мөлаем, ачык, кече һәм йомшак күңелле икән ләбаса. Ул малайга карап елмая.

— Үзең кадәр зур һәм авыр китапны күтәреп ничек килеп җиттең син бу залга? Исемең ничек? — ди музыкант абыйсы малайның башын сыйпап.

Оныгымның кыюсызлыгы, каушавы кар шикелле эреп акты, ул батыраеп китте. Спиваков абыйсы ерактан гына шулай усал шикелле тоелган икән аңа. Кара син аның ап-ак чәчләрен. Алар да елмая шикелле булып китте оныгыма.



Владимир **СПИВАКОВ**, кече һәм олы **Мәгъсүм ГӘРӘЕВ**ләр концерттан соң. 8 декабрь, 2008 ел.

— Владимир Теодорович, бу китапны минем дәү әтием язган. Анда Сезнең турыда хикәятләр, фотосурәтләр дә бар. Рәсемнәр янына автографыгызны куя алмассызмы икән?

Спиваков кулына китапны ала. Актара.

— Исемеңне әйтмәдең бит әле? — дип оныгымны сөйләштерергә тырыша. — Музыканы бик яратасыңмы?

— Мин Мәгъсүм атлы. Музыка мәктәбендә дә укыйм, фортепьянода уйныйм. Хорда җырлыйбыз.

— Китапка автографымны бик теләп куяр идем дә бит, аны мин язмаган шул. Бүтән кеше язган китапка имза кую килешеп бетми. Менә оркестр музыкантлары белән төшкән открыткам бар. Анда барыбыз да күренеп тора. "Киләчәктә зур музыкант булуыңны телибез!" — дип бөтен коллектив исеменнән язам.

— Рәхмәт, зур рәхмәт, Владимир Теодорович.

Спиваков бала күңелле кеше. Аның өч кызы бар. Малайларга мөнәсәбәте бик тә мәрхәмәтле икән бөек дирижерның. Оныгыма бу бик тә ошап китте әле, тагын да кыюланды ул.

— Сез безнең кебек өченче класста укыганда тәртип боза идегезме? — ди Мәгъсүм.

Музыкант абыйсы балачакларына кайткандай үзенә бер күркәмлек белән көлеп алды.

— Малайлар тик кенә тора алмыйлар инде, коридорда да йөгерә идек, тәртипләшкән чаклар да булмады түгел. Ләкин әтәчләнергә вакыт та, ирек тә бирмиләр иде. Минем әтием Уфа авиация заводында инженер иде, аның музыкага берниндн мөнәсәбәте юк. Әнием Ленинградта консерваториядә укыган, пианиночы. Әтием шырпы тартмалары ала. Аларны чәчә. Аннары шул шырпылар белән музыка уйнарга куша. Бу музыка телендә пассаж дип атала. Шашып-шашып шырпылардан музыка чыгарырга азаплануым әле дә булса күз алдымда. Музыка дөньясына кереп китүемдә әтиемнең һәм шушы уенның йогынтысы булмый калмады.

Оныгыма кызык, ул ачылганнан ачыла бара.

— Владимир Теодорович, телевидениедән Сезнең концертларыгызны тыңлаганда, дәү әтинең "Спиваков кебек талантлы дирижер бокс белән дә шөгыльләнгән", — дип әйткәне бар.

— Без, скрипка уйнарга өйрәнүче малайлар, ябык, физик яктан көчсез идек. Куәтлеләр безне саклап тора. Чәкәләшәбез. Әмма безнең беркайчан да җиңгәнебез булмады. Мин моңа бик гарьләнә идем. Берсендә эчкә баткан күкрәгемә карап торам. Ул киерелеп китәргә тиеш. Бокс белән шөгыльләнергә булдым, авыр атлетика белән дә кызыксынып киттем. Әтием штанга сатып алып бирде. Дөрес, ул фатирыбызга сыймый иде. Подъездда торды. Көн саен күрше малайлар белән күтәрә идек. Иртән гантельләр белән зарядкалар ясыйм. Шулай физик яктан чыныгып, көч җыйдым мин. Күптән түгел генә миңа багышланган китап чыкты. Анда спорт белән чын-чынлап мавыгуым турында күп язылган. Кыскасы,

Спиваков корбан гаетен котлый!

спорт белән шөгыльләнүемнең файдасын әле дә тоеп яшим. Концертлардан соң башка дирижерлар кебек арып-талып озак ял итеп утырмыйм. Миңа багышланган китапның авторлары боксчы Спиваков белән Парижда булган бер вакыйганы җентекләп тасвирлаганнар. Сиңа да, нәни дустым Мәгъсүм, сөйләп бирим. Шулай бер кичне хатыным Сати белән атаклы музыкант Мстислав Ростроповичлардан кайтып барабыз. (Мстислав Леопольдович белән дәү әтиең дә яхшы таныш иде. Китабында аның берничә фотосы бар). Вакыт төнге унберләр тирәсе. Кинәттән безнең янга өч егет килеп чыкты. Сатиның сумкасына ябыштылар. Минем кесәгә кермәкчеләр. Мондый чакта мәми авыз булырга ярамый. Берсенә профессиональ бокс удары белән тондырдым. Кесә караклары эшнең җитдилеген сизеп качтылар. Әмма Париж урамында сугышырга ярамый. Моның өчен ике якны да унбиш көнгә төрмәгә ябып куялар. Безнең янга да полиция килеп җитте. "Әгәр сезнең хатыныгызны бандитлар талый башласа, нишләр идегез?" — дим тәртип саклаучыга. "Полиция участогына барып гариза язам", — ди теге. — "Әгәр дә чын ирләрчә боларга отпор бирсәм?" "Ул чагында ике атнага төрмәгә ябалар", — дип аңлата полицейский. Монысы болай гына. Иң кызыгы шул: урамда сугышып ике атна төрмәдә утыруны французлар юмор белән — скрипка уйнау, дип йөртәләр.

Оныгым Мәгъсүм белән бөек скрипкачы һәм дирижер Владимир Спиваковның серләре тәмам килеште бит. Музыкант кече Гәрәевтән интервью ала башлады.

— Син, улым Мәгъсүм, французча өйрәнмисеңме?

— Әлегә юк, мин инглиз телле мәктәптә укыйм.

— Музыка мәктәбендәге уңышларың ничек?

— Концертларда еш катнашам. Яхшы уйныйммы, начармы, анысын бәяләү минем эш түгел. Музыка укытучыларыбыз бәяли уеныбызны.

— Дәү әтиеңнең фотоаппараты бар икән. Бик теләсәң, бергәләп фотога төшәргә мөмкин. Безнең оркестр директоры оста фотограф.

— Гомерлек истәлек булыр иде ул, Владимир Теодорович!..

— Сезнең скрипканы тотып карарга мөмкинме? — дип батыраеп китте оныгым.

— Анысын рөхсәт итә алмыйм. Ул — минем өчен бик кадерле инструмент. Аны Италиянең скрипкалар ясаучы иң атаклы мастеры Страдивари 1712 елда ясаган. Мин аны күз карасыдай саклыйм. Менә бусын, мин дирижерлык итә торган таякчыкны, бармакларың белән капшый аласың. Монысы да шулай ук кадерле. "Виртуозы Москвы" оркестры белән АКШта гастрольдә булганда аны миңа американ дирижер, пианиночы һәм композитор Леопард Бернстайн бүләк иткән иде. Егерме еллап инде шул таякчык белән дирижерлык итәм.

— Мәгъсүм, Казанда тагын концертым булса, килерсеңме?

— Һичшиксез, ул чыгышыгызны түземсезлек белән көтеп калам. Озакка суза күрмәгез. Барысы өчен дә Сезгә, Владимир Теодорович, мең-мең рәхмәт! Гастроль юлларыгызда алсу гөлләр һәрчак чәчәк атып торсын!..

Владимир Спиваковның Казанга килүе бик тә истәлекле көнгә туры килде. Мөселманнарның иң зур бәйрәме Корбан гаете көне кичендә булды искиткеч концерт. Бөек кешеләр һәрвакыт акыллы фикерләре белән балкып алалар. Дирижер кичәне дә бик үзенчәлекле итеп алып барды. Репертуарда Моцарт һәм Чайковскийның бәйрәм музыкасы иде. Гает көнне тамашачының кәефен күтәреп торырга кирәк бит. Антрактка кадәр Маэстро сәхнәгә теге таякчыгын түгел, скрипкасын тотып чыкты. Моның үзенә күрә тирән мәгънәсе бар иде. Корбан бәйрәменең тарихы еракл ардан килә. Дирижерлык итүнең үз үткәне дә шундый. Оркестр белән скрипкачының дирижерлык итүе XVIII гасыр уртасында башлана. Смычок хәзерге чыбыкны хәтерләтә бит һәм аның прообразы булган. Вальс короле Иоганн Штраус та үзенең капелласына скрипкада уйный-уйный җитәкчелек иткән.

Владимир Теодорович Корбан гаете концертында оркестрның баш солисты иде. Бер тамашачыга, бер музыкантларына карап уйнады һәм сиздермичә генә дирижерлык та итте. Димәк, бу һөнәрнең тарихын искә төшерде.

— Залда тылсымлы бер өчпочмак хасил була: музыка-оркестр-тамашачы. Музыкантлар уртада кала. Дирижерның бурычы — боларны бер бөтен итү, ул оркестрчыларга карап эшли. Оркестр дирижер йөзен залга музыка аша күрсәтә, — дип аңлатып куя Спиваков.

Концерт тәмамлангач, зал дирижерны да, оркестрны да сәхнәдән җибәрми. "Виртуозы Москвы" камера оркестрын Владимир Спиваков дирижерлык иткәндә тыңлап туеп буламы соң!? Биш мәртәбә биска уйнагач, алтынчысы алдыннан Маэстро зал белән тарча сөйләшеп алды. "Бүген — Корбан бәйрәме, котлыйм. Хәзер бөек итальян композиторы Вердиның мөселманнар тормышыннан язылган "Аида" операсыннан бер өзек..."

Бу минутларда зал, мөгаен, җиде кат күккә менеп утырган кебек хис иткәндер үзен. Талант, чын талант бөеклеген һәркайчан ача, күрсәтә белә!

"Виртуозы Москвы" камера оркестрын Спиваков 1979 ел башында оештырып җибәргән иде. Һәм авыр елларда да коллективны саклап кала алды. Менә утыз ел инде ул бөтен дөнья буйлап гастрольләрдә йөри. Юбилейга багышланган турнены Казанда башлап, Маэстро безгә зур хөрмәт күрсәтте. "Универсиадага әзерлек матур музыка кебек барсын, ә студентларның Казандагы ярышлары спортка гимн булсын!" — ди Владимир Теодорович саубуллашканда.

Ахырда шунысын да искәртим: Владимир Спиваков, скрипкада уйнап, бик күп халыкара конкурслар лауреаты булды. Аңа СССРның халык артисты исеме бирелде. ЮНЕСКО 2006 елның ноябрь ахырында бөек музыкант Владимир Спиваковка "Бөтендөнья артисты" дигән исемне бирде. Сәнгать кешесе өчен җир йөзендә моннан да мактаулы, моннан да дәрәҗәле исем юк.

ЧАЯН (СКОРПИОН)

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ
1923 елдан чыга.
№ 1 (1669) 2009

«Татмедиа» ААҖ филиалы директоры — баш редактор Рәшит ЗӘКИЕВ.
Редколлегия:
Ринат АБЗАЛОВ, Илдус АЗИМОВ, Александр АЛЕШИН (баш рәссам), Илдар ӘХМӘДИЕВ, Ислам ӘХМӘТҖАНОВ («Идел-Пресс» ААҖ генераль директоры), Юрий БЕЛЯЙЧЕВ, Вячеслав БИБИШЕВ, Мәгъсүм ГӘРӘЕВ, Эрнест ДЫШАЕВ, Минвагыйз ЗӘЙНЕТДИНОВ (җаваплы секретарь), Светлана ПРИВИНА, Виталий ФЕОКТИСТОВ, Рафаэль ХӘЛИЛУЛЛОВ (баш редактор урынбасары), Петр ШАҺРАЙ, Александр ШУЛЬПИНОВ.

Журналның техник редакторы Фания ХАФИЗОВА.
«Чаян»га Татарстанда, Россиядә һәм БДБда барлык элемтә бүлекчәләрендә язылырга мөмкин.
УЧРЕДИТЕЛЬЛӘР:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХӨКҮМӘТЕ, ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ ҺӘМ «ЧАЯН» РЕДАКЦИЯСЕ.
Журнал Татарстан Республикасы матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникация чаралары эшләре министрлыгында теркәлде.
Теркәлү саны — 81.
2009 ЕЛНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЯРТЫ ЕЛЛЫГЫНА «ЧАЯН»НЫҢ ЯЗЫЛУ БӘЯСЕ ТАТАРСТАН КАТАЛОГЫНДА — 108 сум 00 тиен, ТАТАРЧА «ЧАЯН»НЫҢ ИНДЕКСЫ — 73488, РУСЧАСЫНЫКЫ — «ЧАЯН» («Скорпион») — 73489.
Айга ике тапкыр татар һәм рус телләрендә чыга.
Белешмәләр өчен телефоннар: 541-38-93, 292-39-16, тел./факс: 541-38-66.
«Идел-Пресс» басмаханәсе типографиясендә басылды. Декабристлар ур.,2. Казан, 420066.
Басарга кул куелды 29. 12. 2008 ел.
Тираж 6651. Заказ Т- 1690.
Кәгазь форматы 84 x 108 1/16.
Офсет ысулы белән басыла.
Басма табагы 2,1.
Учетн.-изд. табагы 3,01.
Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә җәһәт кенә әзерләнде.
«Чаян»нан иконен күрсәтмичә журнал әсәрләрен файдалану тыела.
Ваклап сату бәясе ирекле.



E-mail: root@chayan.kazan.ru; chayan@bk.ru
Редакциянең һәм нәширнең адресы: «Чаян» редакциясе. Декабристлар ур., 2. Казан, 420066.



Тираж сертификацияләнгән

Уйна да, уйла да!



Тәңкә карлар...



												К	Ы	Ш	Л	А	Р					
								6														

К	Ы	Ш	К	Ы																	
					9																



													К	Ы	Ш				
					1														

										К	Ы	Ш	Л	А	Р	Д	А	Н	
							4												



К	А	Р											
									7				

К	Ы	Ш	К	Ы																		
				5																		

Р. АБЗАЛОВ эше.

													К	А	Р	Л	А	Р				
8				2																		

									К	А	Р	Л	А	Р							
			3																		



Аклы-зәңгәрле горизонтальләргә «кыш» һәм «кар» сүзләре кергән җыр юллары языгыз. Сары шакмакларга ул җырларның исемнәрен тутырыгыз (монда сезгә рәсемнәр һәм аста тәртипсез рәвештә бирелгән фамилияләр исемлеге ярдәм итәр). Ә номерланган шакмакларны тәртип буенча тезгәч, сез бераз көтелмәгәнрәк, ләкин кышка турыдан-туры мөнәсәбәте булган тикшерү сүзен укырсыз.

С. ХӘКИМ • Р. МИҢНУЛЛИН • И. ЮЗЕЕВ • Р. ФӘЙЗУЛЛИН • Ш. ГАЛИЕВ • Ә. АТНАБАЕВ • М. ГАЛИЕВ • Г. ЗӘЙНАШЕВА

Журналыбызның 23 нче санында басылган башваткычның җавабы — **«АЛТЫН ТУЙ».**
Беренче булып дөрес җаваплар җибәрделәр:
Г. АСЕЕВ (Казан),
Д. АСЫЛОВ (Бөгелмә),
Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Яр Чаллы),
Т. ГАЙФУЛЛИНА (Казан),
Ә. ГӘРӘЙХАНОВА (Саба р-ны, Тимершык авылы),
С. МИННЕГАЛИЕВА (Казан),
Г. ӘҺЛИЕВА (Тукай р-ны, Боерган авылы).

Бу турның җиңүчесе — Яр Чаллыдан

Галиәхмәт БАҺАВЕТДИНОВ!

Җаваплар өчен телефон — **292 39 16**

Кадерле укучылар!
“Чаян” сезне Яңа ел белән котлый!





2009

январь 1

дш	сш	чр	пн	җм	шм	як	дш	сш	чр	пн	җм	шм	як
										1	2	3	4
5	6	7	8	9	10	11	12	13	14	15	16	17	18
19	20	21	22	23	24	25	26	27	28	29	30	31	

февраль 2

дш	сш	чр	пн	җм	шм	як	дш	сш	чр	пн	җм	шм	як
													1
2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12	13	14	15
16	17	18	19	20	21	22	23	24	25	26	27	28	

март 3

дш	сш	чр	пн	җм	шм	як	дш	сш	чр	пн	җм	шм	як
													1
2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12	13	14	15
16	17	18	19	20	21	22	23	24	25	26	27	28	29
30	31												

апрель 4

дш	сш	чр	пн	җм	шм	як	дш	сш	чр	пн	җм	шм	як
		1	2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12
13	14	15	16	17	18	19	20	21	22	23	24	25	26
27	28	29	30										

май 5

дш	сш	чр	пн	җм	шм	як	дш	сш	чр	пн	җм	шм	як
				1	2	3	4	5	6	7	8	9	10
11	12	13	14	15	16	17	18	19	20	21	22	23	24
25	26	27	28	29	30	31							

июнь 6

дш	сш	чр	пн	җм	шм	як	дш	сш	чр	пн	җм	шм	як
							1	2	3	4	5	6	7
8	9	10	11	12	13	14	15	16	17	18	19	20	21
22	23	24	25	26	27	28	29	30					

июль 7

дш	сш	чр	пн	җм	шм	як	дш	сш	чр	пн	җм	шм	як
		1	2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12
13	14	15	16	17	18	19	20	21	22	23	24	25	26
27	28	29	30	31									

август 8

дш	сш	чр	пн	җм	шм	як	дш	сш	чр	пн	җм	шм	як
					1	2	3	4	5	6	7	8	9
10	11	12	13	14	15	16	17	18	19	20	21	22	23
24	25	26	27	28	29	30	31						

сентябрь 9

дш	сш	чр	пн	җм	шм	як	дш	сш	чр	пн	җм	шм	як
								1	2	3	4	5	6
7	8	9	10	11	12	13	14	15	16	17	18	19	20
21	22	23	24	25	26	27	28	29	30				

октябрь 10

дш	сш	чр	пн	җм	шм	як	дш	сш	чр	пн	җм	шм	як
										1	2	3	4
5	6	7	8	9	10	11	12	13	14	15	16	17	18
19	20	21	22	23	24	25	26	27	28	29	30	31	

ноябрь 11

дш	сш	чр	пн	җм	шм	як	дш	сш	чр	пн	җм	шм	як
													1
2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12	13	14	15
16	17	18	19	20	21	22	23	24	25	26	27	28	29
30													

декабрь 12

дш	сш	чр	пн	җм	шм	як	дш	сш	чр	пн	җм	шм	як
	1	2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12	13
14	15	16	17	18	19	20	21	22	23	24	25	26	27
28	29	30	31										

дш сш чр пн җм шм як дш сш чр пн җм шм як
дш сш чр пн җм шм як дш сш чр пн җм шм як

Татарстанның күренекле җәмәгать эшлеклесе, язучы-сатирик **Дамир ГЫЙСМЕТДИН**



В. БИБИШЕВ шаржы